**Аннотация к рабочей программе по родному языку.**

Балалар бакчасында татар балаларына ана теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә татар балаларын ана телендә дөрес сөйләмен формалаштыру; туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү; төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

Эш программасы өч бүлектән (максатчанлык, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән. “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында икенче кече яшьтәге балалардан

алып мәктәпкә хәзерлек төркемнәре белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән программа Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Балаларның сөйләмен үстерү “Кроха” программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән  эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелгән. Программа үз эченә “Сөенеч” (авторы: Шаехова Р.К.) төбәк белем бирү программасын да алган.

Ана теле программасы  3-5 яшьлекләр өчен “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплектына  (авторлары: Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ.) нигезләнеп төзелде. 5-7 яшьлекләр өчен “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплектына  (авторлары: Зарипова З.М., Вәҗиева Л.Н., Зөфәрова Р.С., Миншова Н.А., Минһаҗева З.Җ., Хайретдинова Л.Г., Хуҗина А.Т.) нигезләнеп төзелде.

**Программаның максаты:**

Балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру.

**Бурычлар:**

1. Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү.

2.Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру.

3. Бәйләнешле сөйләм үстерү.

4. Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

5. Аваз культурасы тәрбияләү.

6. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру.

**Программа принциплары:**

*Үстерешле белем бирү*- белем бирү нәтиҗәсендә белемнәр үзләштерелеп, күнекмәләр генә формалаштырып калмый, ә тоемлау, аңга алу, хәтер,

игътибар, сөйләм, фикерләү белән бәйләнешле барлык танып белү процессларын да, шулай ук ихтыяр һәм эмоцияләр дә үстерү.

*Коммуникативлык* - телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынайту.

*Белем бирү барышында тәрбияләү.*

*Фәннилек* - мөстәкыйль фикер йөртү, төрле ситуацияләрдә белемнәрен куллана белү, максат кую һәм эш тәртибен билгеләү , фәнни мәгълүматларга таянып, үз фикерләрен дәлилләү, мөстәкыйль эшчәнлек алып бару.

*Эзлеклелек һәм системалылык* – өйрәнеләсе материалларны эзлекле һәм системалы итеп бирү.

*Аңлаешлылык.*

*Гуманлылык* – бала шәхесен ихтирам итү һәм психологик якланганлык хисләре булдыру.

*Күрсәтмәлелек* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү.

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту.

*Индивидуальләштерү принцибы* - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

**Ана телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар:**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, мониторинг буенча материаллар.

2. Тавышлы күрсәтмәлелек (аудиоязмалар, мультфильмнар).

3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар)

4. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)

5. Интерактив уеннар.